**ГЛАВА БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Большой Битаман, ул.Московская, 2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Битаман авылы, Мәскәү ур.,2

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01 ноябрь 2022 г.** **№1**

# Олы Битаман авыл җирелегенең Олы Битаман авылында үзара салым кертү һәм аны куллану турында гражданнар җыеннын билгелү турында

“Рәсәй Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру турында” 06.10.2003 елгы 131-ФЗ Федераль законының 25,1 матддәсе, “Татарстан респуликасын җирле үзидарә” 28.07.2004 45-ЗРТ законының 35 маддәсе, Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы карар итте:

1. Олы Битаман авылында үзара салым кертү һәм аны куллану турында гражданнар җыеннын Олы Битаман авылы, Мәскәү башы урамы. 2В йорт адресы буенча, 2022 елның 15 ноябренә 17.00 сәг. билгеләргә.
2. Гажданнар җыена түбәндәге мәсьәләне раслауны куярга:

«Сез:

1. 2023 елда Олы Битаман авылында 2023 елда һәр балигъ булган, Олы Битаман терртиориясендә рәсми теркәлгән гражданның 1000 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм аны түбәндәге җирле мәсьәләләрне чишүгә кулланырга ризамы:

а) Олы Битаман авылы эчендәге юлларга таш түшәргә

б) Юлларны кыш көне кардан чистартып тотарга

в) Зиратның коймa белән әйләндереп алуга.

2. 2023 елда түбәндәге категория гражданнарны үзара салым түләүдән азат итәргә:

а) Рәсәй Федерациясенеә хәрби көчләренә моблизицияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын

б) 1 төркем инвалидларны

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адреслары буенча урнаштырып халыкка җикерергә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткергән көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ю.Закиров